**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЕ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясепоселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**29.09.2023** **№ 1467**

**Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Ваклап сату базарын оештыру хокукына рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елың 15 декабрендәге 1021 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законга үзгәрешләр кертелүгә бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Ваклап сату базарын оештыру хокукына рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 15 декабрендәге 1021 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3.3.2.1. пунктчаның 11 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Формалаштырган гаризаны формат-логик тикшерү бердәм портал тарафыннан орган (оешма) билгели торган таләпләр нигезендә автомат рәвештә мөрәҗәгать итүче гаризаның электрон формасында һәр юлны тутыру процессында башкарыла. Гаризаның электрон формасында бердәм портал тарафыннан дөрес тутырылмаган юл ачыкланганда, мөрәҗәгать итүчегә ачыкланган хатаның характеры һәм аны бетерү тәртибе турында турыдан-туры гаризаның электрон формасында мәгълүмати хәбәр ярдәмендә җиткерелә.»;

1.2. 2.16 бүлекнең 2.16.1 пунктын түбәндәге эчтәлекле 7 пунктча белән тулыландырырга:

«7) Бердәм портал кулланып, машина укый ала торган форматта орган (оешма) тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ алырга.»

2. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Ваклап сату базарын оештыру хокукына рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2019 елның 28 октябрендәге 1848 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә) һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Биектау муниципаль

районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адрес буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары М.Р. Булгаковка йөкләргә.

Җитәкче Р.Ф. Хәкимуллин